**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘМБАЛЫКЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

2021 ел,15 гыйнвар №1

**«Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарга үзгәрешләр кертү турында»**

«Россия Федерациясе чикләрендә тору һәм яшәү урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәү исәбенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Административ регламентын раслау турында» 2017 елның 31 декабрендәге 984 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 10 августындагы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» гы 10 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 нче кушымтаның 1.5 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган белешмә (күчермә) астында түбәндәгеләр аңлана: гаилә составы турында белешмә, яшәү урыныннан белешмә, хуҗалык кенәгәсеннән өземтә, үлгән кеченә яшәү урыныннан белешмә, шәхси торак йортларда яшәүчеләргә элеккеге яшәү урыныннан белешмә, җир участогына белешмә, йортка белешмә.».

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Апас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Шәмбалыкчы авыл**
**җирлеге башлыгы** **Ф.Ф. Миңнуллин**